## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 18 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегенең Шәрләрәмә авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә авылы территориясендә I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Шәрләрәмә т. п. кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
-МТЗ-320,4 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт өчен түләү);
- бәйрәмнәрне үткәрү өчен призлар, бүләкләр (Сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, 9 Май, яшьләр арасында хоккей ярышлары);
- Шәрләрәмә авылында пожар гидрантлары урнаштыру
- Шәрләрәмә авылында Бөек Ватан сугышы ветераннары йортына мемориаль такта сатып алу.;
- Шәрләрәмә авылы зиратын эйлэндереп алу очен профнастил сатып алу хэм урнаштыру;
- Шәрләрәмә авылында биек агачларны кису.

3. Әлеге карарны Шәрләрәмә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.Н.Хужина